## Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы мәсьәләләре», 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары

2011 ел, 27 август; 2012 ел, 18 октябрь, 21 август; 2013 ел, 19 март, 28 октябрь, 28 декабрь; 2014 ел, 26 март; 2016 ел, 16 июнь, 19 август, 27 октябрьда кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып.

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турында» 2011 ел, 1 июнь, УП-298 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар бирә:

1. Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турында нигезләмәне һәм аның структурасын бәян итергә.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 16 июнь 407 нче карары белән әлеге карарның 2 нче пунктына үзгәрешләр кертелде*

*Моннан алдагы редакциядә пункт текстын карагыз*

2. Билгеләргә:

бөтен хезмәт урыннары буенча 156,05 мең сум тәшкил иткән айлык хезмәт хакы фонды булган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгының эшчеләр санын 30 берәмлектә;

Агентлыкның хезмәт җиңел машиналары лимиты 4 берәмлектә.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2014 ел, 26 март 189 нчы карары белән әлеге карарның 3 нче пунктына үзгәрешләр кертелде*

*Моннан алдагы редакциядә пункт текстын карагыз*

3. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына ике җитәкче урынбасар, алар арасында бер беренче урынбасар булырга рөхсәт ителә.
4. Татарстан Республикасының Финанслар министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетында каралган Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына 2011 елга кирәк булган акча кысаларында әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны закон белән билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итергә.
5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчен югалтуын танырга:

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларга үзгәрешләрне кертү турында" 2009 ел, 27 март 177 нче карары;

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше буенча комитеты мәсьәләләре" 2008 ел, 19 март 175 нче карарына үзгәрешне кертү турында" 2010 ел, 5 июль 533 нче карары;

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше буенча комитеты мәсьәләләре" 2008 ел, 19 март 175 нче карарына үзгәрешне кертү турында" 2010 ел, 2 декабрь 978 нче карары;

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше буенча комитеты мәсьәләләре" 2008 ел, 19 март 175 нче карарына үзгәрешне кертү турында" 2011 ел, 10 февраль 82 нче карары.

6. Әлеге карарны башкаруны контрольда тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасының И.Ш. Халиков
Премьер-министры

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*
*ТР МК 2014 ел, 16 июнь 407 нче карары белән әлеге Нигезләмә яңа редакциядә бәян ителгән*
*Моннан алдагы редакциядә пункт текстын карагыз*

## Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы турында нигезләмә (ТР МК 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән расланган)

2011 ел, 27 август; 2012 ел, 21 август, 18 октябрь; 2013 ел, 19 март; 2016 ел, 16 июнь, 19 август, 27 октябрьда **кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып**.

### 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба – Агентлык) инвестицион проектларны алып бару һәм тормышка ашыру, Татарстан Республикасының инвестицион сөйкемлелеген арттыру һәм яхшы инвестицион климатын формалаштыруда катнашу, дәүләт-хосусый партнерлык (муниципаль-хосусый партнерлык) турында килешүләр, концессион килешүләр, яшәү циклы контрактлары, башка инвестицион килешүләр нигезендә тормышка ашырылучы проектларны кертеп инвестицияләрне җәлеп итү сораулары буенча вәкаләтләрне башкаручы Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы булып тора (Татарстан Республикасының идарәсе).

1.2. Агентлык Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән аралашуда эшчәнлеген алып бара.

1.3. Агентлык үз вәкаләтләре кысаларында оештыру-хокук формалары һәм урнаштырырлган эшчәнлегендә идарәле булуга карамастан эшханәләр, оешмалар һәм учреждениеләр белән аралаша.

1.4. Агентлык Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасының Конституциясе, Татарстан Республикасының кануннары, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президентының карарлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хакимияте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.5. Агентлык юридик шәхес булып тора, үз балансы, исеме, Татарстан Республикасының Дәүләт Гербы сүрәте бар, кыскартлыган исеме – ИҮА, канунчылыкка туры килеп ачылган счетлар бар.

1.6. Агентлык урнашкан (юридик адрес): 420049, Казан шәһәре, Агрономия урамы, 11 йорт.

### 2. Агентлык бурычлары

2.1. Агентлыкның төп бурычлары:

2.1.1. Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион программалар һәм проектларны тормышка ашыру һәм алып бару буенча Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарының аралашуын тәэмин итү.

2.1.2. Социаль-мәдәни һәм торак-коммуналь максатта объектларны урнаштыру өчен дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир участокларын арендага бирү буенча чараларны тормышка ашыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру.

2.1.3. Татарстан Республикасында инвестицион климатын яхшырту буенча чараларны тормышка ашыру.

2.1.4. Татарстан Республикасының икътисад үсеше һәм конкурентлыкны арттыру максатында инвестицион активлыкны стимульләштерү буенча чараларны уйлап табу һәм тормышка ашыруда катнашу.

2.1.5. Республика инвестицион программалар һәм проектларны уйлап табуда катнашу.

2.1.6. Икътисадның приоритетлы секторларына инвестицияләрне җәлеп итү өчен яхшы шартлар булдыру аша Татарстан Республикасы икътисадының диверсификацияләүгә ярдәм итү.

2.1.7. Инвестицияләрне җәлеп итү өлкәсендә Татарстан Республикасының халыкара һәм регионара тышкы икътисади элемтәләрне үстерү.

2.1.8. Татарстан Республикасының инвестицион сөйкемлелек комплекслы анализын алып бару.

2.1.9. Инвестицияләрне җәлеп итү өлкәсендә Татарстан Республикасының конгресс-күргәзмә эшчәнлеген үстерүдә катнашу.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 27 октябрь 789 нчы карары буенча әлеге карарның 2.1 пунктына 2.1.10 пункты кушылды*

2.1.10. Дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтле орган хокукларын алу.

## 3. Агентлык функцияләре

3.1. Агентлык төп функциясе – хосусый инвестицияләр һәм дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсендә инвестицион эшчәнлек үсеше белән идарә итү өчен җавап бирә (01.18*).

3.2. Агентлык аралаша:

Татарстан Республикасының икътисад министрлыгы белән - түбәндәге функцияләрне башкарганда:

инвестицион эшчәнлекнең дәүләт ягыннан көйләү (01.10*);

инвестицион эшчәнлек үсеше белән идарә итү (01.11*);

иҗтимагый-икътисади программалаштыру (01.01*);

Татарстан Республикасының финанслар министрлыгы белән – бюджет процессы белән идарә итү функциясен башкарганда (Татарстан Республикасының һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджеты) (01.02.1*);

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән - түбәндәге функцияләрне башкарганда:

Татарстан Республикасының тышкы икътисади эшчәнлек һәм ватандашлар белән мөнәсәбәтләр өлкәсендә эшчәнлек белән идарә итү (01.03*);

Татарстан Республикасының вәкиллекләре һәм сәүдә йортлары эшчәнлеген үзара килешкәнлек итү (01.03.1*);

сәнәгать белән идарә итү (03.01*);

иҗтимагый-икътисади хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарының Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары белән билгеләнгән тәртиптә аралашуны тәэмин итү (03.07*);

Татарстан Республикасының җир һәм мөлкәт министрлыгы белән - түбәндәге функцияләрне башкарганда:

Татарстан Республикасы милегендә булган күчемсез мөлкәт (йортлар, биналар), транспорт, җиһаз, мәдәни мирас объектларын куллану белән идарә итү (01.07.01*);

Татарстан Республикасы милегендә булган приватизацияләнгән мөлкәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү (01.07.03*);

Татарстан Республикасының җир ресурслары белән идарә итү (01.07.04*);

Иҗтимагый-икътисади мониторинглау буенча Татарстан Республикасының комитеты белән - иҗтимагый-икътисади мониторинглау нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функцияләрен башкарганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән - Татарстан Республикасының идарә дәүләт мәгълүмати ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функцияләрен башкарганда (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән идарә итү функцияләрен башкарганда (03.02.01*);

Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак- коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – торак-коммуналь хезмәт һәм торак базарларын формалаштыру өчен шартларны булдыру функцияләрен башкарганда (04.01.01*);

Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән – муниципальара мөһимлегендә булган уртак куллану автомобиль юллары, күперләр һәм башка региональ мөһимлегендә булган транспорт һәм инженер корылмаларны төзү, ремонтлау, карау, реконструкция белән идарә итү функцияләрен башкарганда (03.03.01*);

Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә итү функцияләрен башкарганда (04.09*).

## 4. Агентлык вәкаләтләре

4.1. Агентлык үз вәкаләтләре кысаларында әлеге Нигезләмәнең 3 нче бүлегенә туры килеп түбәндәге вәкаләтләр башкара:

4.1.1. Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләрне җәлеп итү, шулай ук Татарстан Республикасының инвестицион сөйкемлелеген арттыру буенча чаралар үткәрә.

4.1.2. Дәүләт-хосусый партнерлык (муниципаль-хосусый партнерлык) турында килешүләр, концессион килешүләр, яшәү циклы контрактлары, башка инвестицион килешүләр нигезендә тормышка ашырылучы проектларны кертеп инвестицияләрне җәлеп итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимият башкарма органнары эшчәнлеген үзара килешкәнлек итә.

4.1.3. Татарстан Республикасының инвестицион программаларын гамәлгә ашыру өчен чит ил дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган финанс институтлары белән аралаша.

4.1.4. Татарстан Республикасының Инвестицион советы һәм аның президиумының проектларны карауны кертеп “бер тәрәзә” принцибы буенча инвестицион проектларны алып бару системасының эшләвен тәэмин итә.

4.1.5. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территорияләрендә яхшы инвестицион климатны булдыру буенча чараларны гамәлгә ашыру һәм инвестицион үсеш программаларын уйлап табуда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренең үзидарәләре органнарына методик ярдәм итә.

4.1.6. Дәүләт ягыннан ярдәм күрсәтү максатында инвестицион проектларны билгеләнгән тәртиптә сайлый һәм аларны гамәлгә ашыруны мониторингта тота.

4.1.7. Инвестицион эшчәнлек субъектларына консультацион, мәгълүмати һәм хокук ярдәмен күрсәтә.

4.1.8. Яхшы инвестицион климатны булдыру максатында инвестицион эшчәнлек субъектлары белән аралаша.

4.1.9. Инвестицион проектларның оештыру процессын алып бара, шулай ук рөхсәт документациясен алуда һәм проектлы документациясен әзерләүдә инвесторларга ярдәм күрсәтә.

4.1.10. Халыкара оешмалар, чит илләрнең административ-территориаль берәмлекләр, чит ил федератив дәүләтләр субъектлары белән тышкы икътисади һәм халыкара элемтәләрне башкару турында Татарстан Республикасының килешү проектларын эшләп чыгара.

4.1.11. Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлек турында мәгълүматны актуализацияләү максатында Татарстан Республикасының Инвестицион порталын алып баруын башкара.

4.1.12. Инвестицион эшчәнлек өлкәсендә финанс-кредит оешмалар белән аралаша.

4.1.13. Инвестицион инфраструктураны формалаша һәм аның эшчәнлеген тәэмин итә.

4.1.14. Инвестицион эшчәнлек мәсьәләләренә караган норматив хокук актлары проектлары буенча тәкъдимнәр бирә һәм тикшенүне үткәрә.

4.1.15. Татарстан Республикасы Президентының боерыгына туры килеп сәүдә итмичә җир участокларын арендага бирү өчен Татарстан Республикасының Җир кодексы һәм Татарстан Республикасы Президентының “Сәүдә итмичә җир участокларын арендага бирү өчен мөмкин булган, масштаблы инвестицион проектларның туры килгән сыйфатлы һәм санлы критериеләр күрсәткечләрен билгеләү турында” 2015 ел, 7 декабрь УП-1170 нчы Указы билгеләгән масштаблы инвестицион проект, иҗтимагый-мәдәни һәм коммуналь-

көнкүреш объектның критериеләргә туры килүен нигезләгән документларны кабул итү һәм карауны башкара.

4.1.16. Масштаблы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру, иҗтимагый-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларны урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Президентының боерыгына туры килеп сәүдә итмичә җир участогын арендага бирү турында үтенечләрне кабул итә.

4.1.17. Масштаблы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру, иҗтимагый-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларны урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Президентының боерыгына туры килеп сәүдә итмичә җир участогын арендага бирү турында үтенечләр булган юридик шәхесләрнең мөрәҗәгатьләр реестрын алып бара.

4.1.18. Инвестицияләрне җәлеп итүгә комачаулаган нигезләнмәгән административ киртәләрне бетерү буенча дәүләт чараларны эшләп чыгару һәм гамәлгә ашыруда катнаша.

4.1.19. Инвестицияләрне җәлеп итү өлкәсендә җәмгыяви фикер соравы, конкурслар, семинарлар, конференцияләр, күргәзмәләрне үткәрүне оештыра, Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион эшчәнлек үсеше белән бәйле сораулар буенча массакүләм матбугат чаралары белән аралаша, Агентлыкның иң мөһим эшчәнлек өлкәләре турында Татарстан Республикасы халкына мәгълүмат бирүен тәэмин итә.

4.1.20. Инвестицион эшчәнлек мәсьәләләре буенча чит ил административ-территориаль берәмлекләр һәм халыкара оешмалар белән билгеләнгән тәртиптә хезмәттәшлек итә.

4.1.21. Татарстан Республикасының инвестицион мөмкинлекләрен алга таба үстерү һәм инвестицион потенциалын үстерү кысаларында Татарстан Республикасы җитештерүчеләрнең товарлары (эшләр, хезмәт) һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен чит ил базарларына алга таба үстерү өчен шартлар булдыра.

4.1.22. Инвесторлар өчен яхшы шартлар булдыру буенча чараларны финанслауга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән финанс ресурслар белән билгеләнгән тәртиптә эш алып бара.

4.1.23. Инвестицион эшчәнлек субъектларының икътисади, статистик, җитештерү-технологик, хокук һәм башка мәгълүмат алуны тәэмин итүче мәгълүмати системаларны формалаштыру буенча эшне оештыра.

4.1.24. Закон белән билгеләнгән вәкаләтле органнар белән бергә инвестицион эшчәнлек субъектларына финанс, мөлкәт һәм башка ярдәм күрсәтүдә катнаша.

4.1.25. Татарстан Республикасының индустриаль һәм сәнәгый парклар һәм мәйданнар, махсус икътисади зоналарга резидентларны җәлеп итүгә булыша.

4.1.26. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә координацион һәм киңәшмә органнарны булдыра.

4.1.27. Үз вәкаләте кысаларында билгеләнгән тәртиптә методик документлар, норматив хокук актлары проектлары, программалар, концепцияләр һәм аналитик материалларны эшләп чыгаруга фән, белем, консалтинг һәм башка оешмаларны җәлеп итә.

4.1.28. Агентлык вәкаләтенә кагылган сораулар буенча юридик шәхесләр һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары белән эш итә.

4.1.29. Башкарма хакимият федераль органнары, аларның территориаль органнар, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, башка Россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән үз вәкаләте кысаларында барлыкка килгән килешүләр һәм башка публика-хокуклы актлар реестрын алып бара.

4.1.30. Һәр елны, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының ришвәтчелеккә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына ришвәтчелеккә каршы сәясәте чараларын гамәлгә ашыру турында отчет бирә.

4.1.31. Карамагындагы булган Татарстан Республикасының дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрне оештыручы вәкаләтләре һәм функцияләрен башкара (алга таба – дәүләт учреждениеләр).

4.1.32. Карамагындагы булган дәүләт учреждениеләрне булдыру, үзгәртү, бетерү турында карар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәртүләр кертә.

4.1.33. Төп эшчәнлек төрләре белән дәүләт учреждениесенең каралган уставына туры килеп юридик һәм физик шәхесләр белән дәүләт хезмәт күрсәтүгә (эш башкаруга) дәүләт учреждениесенә дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый.

4.1.34. Дәүләт учреждениеләре биргән дәүләт хезмәт сыйфатының стандартларын эшләп чыгаруда катнаша.

4.1.35. Һәр елны карамагында булган дәүләт учреждениеләр биргән дәүләт хезмәте сыйфатының Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтенең билгеләнгән сыйфат стандартына туры килүенә бәя бирә.

4.1.36. Үз вәкаләте кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын башкару методикасына туры килеп Татарстан Республикасының хокук кулланылышын мониторинглауны башкара.

4.1.37. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы канунчылыкларында билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтенә кергән мәсьәләләр буенча язу һәм сөйләм формасында хокук киңәш бирү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм бирә;

Россия Федерациясенең билгеләнгән федераль законнары һәм башка норматив хокук актлары раслаган тәртиптә һәм очракларда гаризалар, үтенечләр һәм шикаятьләр рәвешендә иҗтимагый ярдәмдә һәм иҗтимагый саклауда мохтаҗ булган гражданнарга түләүсез юридик ярдәм бирә, аның ихтыяҗлары исеменнән судта, дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда эш алып бара.

4.1.38. Үз вәкаләте кысаларында Агентлыкка караган объектларның террористларга каршы саклануны тәэмин итә, терроризм һәм экстремизмга каршы эшчәнлектә катнаша.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 27 октябрь 789 нчы карары буенча әлеге Нигезләмәнең 4 нче пунктына 4.2 пункты кушылды*

4.2. Дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләрен башкара, алар арасында:

4.2.1. Татарстан Республикасы ачык партнеры булган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешәүне яисә Татарстан Республикасы катнашуы белән бердәм конкурсны үткәрергә планлаштырылган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары эшчәнлеген идарәара үзара килешкәнлеген тәэмин итә (Россия Федерациясе катнашуы белән бердәм конкурс үткәрүен исәпкә алмыйча);

4.2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимият башкарма органы тәкъдимне эшләп чыгару инициаторы булган чакта ачык партнеры белән бергә дәүләт-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәрне карауны оештыра.

4.2.3. Татарстан Республикасы ачык партнеры булган дәүләт-хосусый партнерлык проектының эффективлыгына бәя бирә, Федераль закон нигезләмәләренә туры килеп әлеге проектның чагыштыручы өстенлекләрен билгели;

4.2.4. Татарстан Республикасы ачык партнеры булган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүне булдыру өчен конкурсны үткәрү өчен конкурс документациясен ачык партнерга яраштыра;

4.2.5. Дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләрне гамәлгә ашыру мониторингын үткәрә;

4.2.6. Дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләрне гамәлгә ашыруда ачык һәм хосусый партнерларның закон ихтыяҗларын һәм хокукларын сауклауга ярдәм итә;

4.2.7. Булдырылган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләр реестрые алып бара;

4.2.8. Татарстан Республикасы ачык партнеры булган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешүләрнең ачык һәм һәркем белерлек булуын тәэмин итә;

4.2.9. Татарстан Республикасы ачык партнеры булган дәүләт-хосусый партнерлык турында килешү яисә Татарстан Республикасы катнашуы белән үткән бердәм конкурс нигезендә барлыкка килгән килешүне гамәлгә ашыру мониторингының нәтиҗәләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башкарма хакимият федераль органына бирә.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 27 октябрь 789 нчы карары буенча әлеге Нигезләмәнең 4 нче пунктына 4.3 пункты кушылды*

4.3. Дәүләт-хосусый партнерлык өлкәсендә Татарстан Республикасы Законы һәм Федераль закон, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән каралган башка вәкаләтләрне башкара.

## 5. Агентлык хокуклары

5.1. Агенлык аңа тапшырылган мәсьәләләрне үтү өчен хаклы:

5.1.1. Агентлык эшләвенә акча тоту, дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга караган Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы һәм җаваплы оештыручы вәкаләтләрен башкарырга.

5.1.2. Татарстан Республикасының дәүләт иҗтыяҗларын тәэмин итү өчен хезмәт, товарларны сатып алуда дәүләт заказ бирүчесе булырга.

5.1.3. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет канунчылыкларына туры килеп Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион активлыкны стимульләштерү мәсьәләләре буенча канунчылыкка туры килгән вәкаләтле органнар белән аралашырга.

5.1.4. Агентлык балансына бирелгән мөлкәт белән оператив идарә итүне башкарырга.

5.1.5. Агентлык эшчәнлеген башкару өчен кирәк булган материаллар һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә сорарга.

5.1.6. Инвестицион эшчәнлек мәсьәләләре буенча норматив хокук актлары проектларын ярашытырырга.

5.1.7. Билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләте кысаларында килешүләр булдырырга һәм сөйләшүләр үткәрергә.

5.1.8. Агентлык җаваплы мәсьәләләрне чишү өчен җитәкчеләр белән яраштырып Татарстан Республикасының дәүләт хакимият башкарма органнар,фәнни-тикшеренү һәм башка оешмалар белгечләрен җәлеп итергә.

5.1.9. Агентлыкның проектлары һәм программаларын тәэмин итү өчен ышанычлык һәм җаваплылыкны бирү, кредитлау, финанслау өчен кредит оешмалар, фондлар һәм башка юридик шәхесләрне килешү нигезендә билгеләнгән тәртиптә җәлеп итергә.

5.1.10. Билгеләнгән тәртиптә җәмгыяви советлар, эшлекле комиссияләр, фәнни- консультатив һәм эксперт группаларын булдырырга.

5.1.11. Киңәшмәләрне җыерга һәм аларда катнашырга, Агентлык вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне кертергә.

5.1.12. Инвестицион эшчәнлек, инвестицион программалар һәм проектларны гамәлгә ашыру мәсьәләләрен кертеп федераль, республика һәм башка оешмалар үткәргән киңәшмәләр, конференцияләр, “түгәрәк өстәл” утырышлары һәм башка чараларда катнашырга.

5.1.13. Агентлык өлкәсендә булган ихтыяҗларын саклау өчен гомуми юрисдикциядәге судлар, арбитраж судында Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән һәм аның йомышы буенча арадашчы вәкил булырга.

5.1.14. Татарстан Республикасы Хөкүмәте йомышы буенча төрле формадагы милек оешмаларын булдырырга.

5.1.15. Канунчылыкка туры килеп башка хокуклар алырга.

## 6. Агентлык эшчәнлеген оештыру

6.1. Агентлык “Татарстан Республикасы дәүләт хакимият башкарма органнары турында” Татарстан Республикасы Законы билгеләгән тәртиптә хезмәткә билгеләнә һәм хезмәт нвазыйфасыннан азат ителүче җитәкче башында тора.

Агентлыкт җитәкчесе тәкъдиме буенча җитәкчедә Татарстан Республикасы Хөкүмәте карары буенча хезмәткә билгеләнә һәм хезмәт нвазыйфасыннан азат ителүче җитәкче урынбасарлары бар.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 27 август 572 нче карары буенча әлеге Нигезләмәнең 6.2 нче пунктына үзгәрешләр кертелде*

*Моннан алдагы редакциядә пункт текстын карагыз*

6.2. Агентлык җитәкчесе:

Агентлык эшчәнлеген оештыра һәм Агентлык тапшырылган вәкаләтләрен һәм аның үз функцияләрен башкару өчен җаваплы;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимият органнары, федераль дәүләт хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, халыкара оешмалары, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларда Агентлык ихтыяҗлары исеменнән эш алып бара;

җитәкче урынбасарлары арасында вәкаләтләрен билгели;

Агентлыкның структура бүлекләре турында нигезләмәне раслый, Агентлык эшчеләрен билгеләнгән тәртиптә эшкә ала һәм вазифаларыннан азат итә;

билгеләнгән эшчеләр саны, хезмәт хакы фонды һәм бюджет кысаларында штат расписаниесен һәм Агентлыкның эшчәнлеге өчен кирәк булган чыгымнар сметасын билгели;

үз вәкаләтләре кысаларында Агентлык эшчеләре башкару өчен боерыклар чыгара, кагыйдәләр билгели, аларның башкаруын контрольда тота;

Агентлык исеменнән дәүләт органнарда, оешмаларда ышанычнамәсез эш алып бара , ышанычнамәләрне бирә, банкларда счетлар ача;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте утырышлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм вазыйфалы шәхесләр киңәшмәләрендә Агентлык эшчәнлегенә караган мәсьәләләр буенча катнаша;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм вазыйфалы шәхесләргә Татарстан Республикасы хокук актлары проектларын күрсәтә, Татарстан Республикасы канунчылыгын яхшырту буенча, Агентлык эшчәнлегенең башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр бирә;

Агентлык җитәкчесе боерыгы раслаган эффективлык күрсәткечләре исемлеге нигезендә җитәкче урынбасарлары, структура бүлекләре җитәкчеләре һәм аның хезмәтчеләренең эшчәнлек эффиктивлыгына бәя бирә;

6.3. Агентлыкта эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча тәкъдимнәрне эзерләү өчен коллегия булдырыла, аның төп максаты Агентлыкка бирелгән дәүләт идарә функцияләрен башкару белән бәйле төп мәсьәләләрне чишү булып тора;

Коллегиянең составы һәм санын Татарстан Республикасы Хакимияте карары буенча раслана.

6.4. Агентлыкта инвестицион программалар һәм проектларны алып бару һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча шулай ук идарәара координацион һәм киңәшмә органнары (киңәшмәләр, комиссияләр, эшлекле группалар) оештырыла ала.

Агентлык җитәкчесе фәнни-консультацион, эксперт һәм башка советлар составын, шулай ук алар турында нигезләмәләрне раслый.

Агентлык аппараты әлеге советлар эшчәнлегенең оештыру-техник тәэмин итүен башкара.

## 7. Агентлык милеге

7.1. Агентлыкка оператив идарә итү хокукында бирелгән милек Татарстан Республикасының дәүләт милеге булып тора һәм Агентлык балансында карала.

7.2. Агентлык барлыкка китерә торган мәгълүмати ресурслар Татарстан Республикасының милеге булып тора.

* “Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре Кодификаторын раслау турында” **2006 ел, 2 май, №220** Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары буенча Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре Кодификаторы буенча кодны билгеләү.

*Үзгәрешләр турында мәгълүмат:*

*ТР МК 2016 ел, 16 июнь 407 нче карары буенча әлеге Структура яңа редакциядә аңлатып бирелгән*

*Моннан алдагы редакциядә пункт текстын карагыз*

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы структурасы**
**(ТР МК 2011 ел, 6 июнь, 460 нчы карары белән расланган)**

2012 ел, 18 октябрь, 2014 ел, 26 март, 2016 ел, 16 июньнән **кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып.**

Җитәкче

Җитәкченең беренче урынбасары

Җитәкченең урынбасары

Инвестицион проектларны Мәгълүмати-аналитик Юридик экспертизалау бүлеге
бүлеге бүлеге

Инвестицион проектларны алып бару бүлеге

Массакүләм матбугат чаралары белән эш итү

Финанс хисабы һәм дәүләт сатып алулар бүлеге

Дәүләт-хосусый партнерлык үсеше бүлеге

Материаль-техник тәэмин итү секторы